| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР<br>422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ<br>422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15 |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 19 ноябре №22

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең шәһәр төзелешен проектлау буенча җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кумара муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясына таянып, шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларны раслауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларны әзерләү, раслау тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адрес буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре Мэры С.Д. Димитриев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД КУКМОР КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ * ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ * Совет города Кукмор ИНН 1623001434 Кукмара Шәһәре Советы

Кукмара шәһәр Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 22 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибе турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларны әзерләү, раслау тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативлар (алга таба – җирле нормативлар) җирлекнең түбәндәге өлкәләргә карый торган җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгели: җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү, җирлек чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, транспорт хезмәте күрсәтү, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәгълүматлаштыру һәм элемтә, мәдәният һәм ял оештыру, социаль тәэминат һәм социаль яклау, физик культура һәм массакүләм спорт, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү, җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле башка өлкәләре; һәм җирлек халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган кадәр үтемле булу дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен билгели.

1.3. Җирле нормативларда кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең минималь исәп-хисап күрсәткечләре Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыруның республика нормативларындагы кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең исәп-хисап күрсәткечләренә караганда түбәнрәк була алмый.

## 2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең шәһәр төзелешен проектлау буенча җирле нормативларны әзерләү һәм раслау тәртибе

2.1. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.

2.2. Җирле нормативлар проектын әзерләү турында карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

- җирле нормативлар проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә;
- җирле нормативлар проектын әзерләү сроклары;
- кызыксынган затларның җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрен җибәрү һәм карау тәртибе;

- җирле нормативларны әзерләү буенча эшләрне оештыруның башка мәсьәләләре.

Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар белән җирле нормативларны әзерләүгә техник бирем раслана.

2.3. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, кабул ителгән көннән биш көн эчендә бастырылырга тиеш.

2.4. Җирле нормативларны әзерләү, җирле нормативларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар кертә ала.

2.5. Җирле нормативларны әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, норматив техник документлар, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлау буенча республика нормативлары нигезендә, түбәндәгеләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

- Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә социаль-демографик составын һәм халык тыгызлыгын;

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнарын һәм программаларын;

- җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәрен.

2.6. Җирле нормативлар проекты «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми порталында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, расланганчы кимендә ике ай эчендә бастырылырга тиеш.

2.7. Кызыксынган затлар җирле нормативлар проекты буенча үз тәкъдимнәрен тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән җирле нормативлар проекты Кукмара муниципаль районының махсуслаштырылган оешмалары белән килештерелергә тиеш.

2.9. Җирле нормативлар проектын килештерү нәтиҗәләре әзерләнгән проектның техник биремгә, норматив техник документларга, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына туры килүе турында Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бәяләмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.10. Башкарма комитет әлеге Нигезләмәнең 2.8 пунктында күрсәтелгән бәяләмәне әзерләгән көннән биш көн эчендә җирле нормативларның расланган проектын Кукмара муниципаль районы Шәһәр Советы каравына кертү турында карар кабул итү өчен Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Мэрына җибәрә.

2.11. Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәр Советы җирле нормативларны раслый. Раслау турындагы карар «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми порталында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, аны кабул иткән көннән өч көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

2.12. Җирле нормативларны раслау турында Карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты,

әлеге карарны, расланган җирле нормативларны кушып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә район әһәмиятендәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелеше проектлары нормативларын системалаштыруны тәэмин итү өчен, шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә.